**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ НОВОАЛИМОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт.

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«15» октябрь 2020 ел** **№7**

**Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2020 ел, 263-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 20 июнендәге 9 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлегендә бюджет процессы нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-«2. Авыл җирлеге Советының тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм бюджет турында закон проектын (карарларны) закон чыгару (вәкиллекле) органына карауга керткәннән соң кабул ителгән норматив-хокукый актлары агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә чираттагы финанс елында исәпкә алына.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Яңа Әлем авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга»

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Яңа Әлем авыл җирлеге Советы белән рәислек итүче Д.М.Әнвәрова